Татарстан Республикасы
Әлмәтмуниципальрайонының
Баграж-Никольскийавыл Советы

# КАРАРЫ

03 март 2020ел

№ 115

Татарстан РеспубликасыӘлмәтмуниципаль районыБаграж-Никольскийавыл Советының 2019 елның23октябреннңәге «Татарстан РеспубликасыӘлмәтмуниципаль районыБаграж-Никольскийавыл Советы җирлегенә керүче торакпунктларында гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турынданигезләмә хакында»гы 103 номерлы карарынаүзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясын, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясын һәм Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Баграж-Никольский авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясын гамәлгә ашыру максатларында

Баграж-Никольский авыл Советы КАРАРБИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Баграж-Никольский авыл Советының 2019 елның 23 октябрендәге «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Баграж-Никольский авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә хакында»гы 103 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.2.5. пунктта «(2 нче кушымта)» сүзләрен «(үзара салым мисалында2 нче кушымта үрнәге)» сүзләренә алмаштырырга, «(3 нче кушымта)» сүзләрен «(үзара салым мисалында3 нче кушымта үрнәге)» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 2.9.2.пунктында пунктында «(5, 6 нчы кушымталар)» сүзләрен «(үзара салым мисалында5 нче, 6 нчы кушымта үрнәкләре)» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 3.1 пунктының беренче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Җыенга килгән гражданнар җыенны оештыручы тарафыннан теркәлә һәм торак пунктта яшәүчеләр һәм җыенда катнашырга хокуклы затлар исемлеге белән чагыштырыла»

1.4. 3.3. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.Исемлектә төгәлсезлекләр барлыгы ачыкланган очрактасайлау хокукына ия булган торак пунктта яшәүче граждан шәхесен раслый торган документлар нигезендә җыенда катнаша ала»;

1.5. 3.8. пунктында «(7 нче кушымта)» сүзләрен «(үзара салым мисалында 7 нче кушымта үрнәге)» сүзләренә алмаштырырга;

1.6. 3.17. пунктында җәя эчендәге (14 нче беркетмә) сүзләрен (14 нче кушымта) сүзләренә алмаштырырга;

1.7. 3.18 пунктта «җирлек башлыгы тарафыннан имзалана торган» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.8. 4.2. пунктын түбəндəге редакциядə бəян итəргə:

«4.2. Җыенда кабул ителгəн карарлар муниципаль норматив хокукый актлар булып тора, гражданнар җыенында рəислек итүче тарафыннан имзалана һəм Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертелергə тиеш.»

1.9.4.5. пунктында «(үзара салым мисалында 15 нче кушымта үрнəге)» сүзлəрен өстəргə;

1.10. Татарстан Республикасы Әлмəт муниципаль районы Баграж-Никольский авыл Советының 2019 елның 23 октябрендəге 103 номерлы карарына кушымтаны əлеге карарга 15 нче кушымта белəн тулыландырырга.

1.11. Нигезлəмəгəкушымталарда «Иванова Светлана Ивановна - ФАП мөдире», «Иванов Иван Ивановичны», «Петрова Полина Петровнаны» сүзлəрентөшерепкалдырырга.

2. Әлеге карарны Дальняя Ивановка авылы, Яшьлəр урамы, 26 нчы йорт; Баграж-Никольский авылы, Үзəк урам, 31б йорты авылы территориясендə урнашкан махсус мəгълүмат стендларында халыкка игълан итəргə, Татарстан Республикасының хокукый мəгълүматлар рəсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмəт муниципаль районы сайты «Интернет» челтəрендə урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтəлешен тикшерүдə тотуны авыл җирлеге башлыгына йөклəргə.

Баграж-Никольский авыл җирлеге
Башлыгы вазыйфаларын башкаручы А.В. Исаев

Татарстан Республикасы Әлмәт
муниципаль районы Баграж-Никольский
авыл Советының 2019 елның
03 мартындагы 115 нче номерлы
карарына кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы____________ авыл җирлегенең ________________ торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы карары

___________ 20__ ел №........

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 20____елның "____"_______________ сәгать 00 минутта, 20____елның "____"____________ ____ сәгать 00 минутта узган гражданнарның этаплы җыен нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге сораулар буенча ------------------------------------------------------------------------------------------------------------------------------------------------ гражданнар җыены беркетмәсе төзелде

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә ____ кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны ____ кеше, бу ___% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның _____ "РИЗА" позициясе өчен тавыш бирде; гражданнар җыенында катнашучыларның _____ "КАРШЫ" позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы ___________ авыл җирлегенең __________________ торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы________ авыл җирлегенең _________________ авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, даими яшәүче булган һәр балигъ булган кешедән үзара салым средстволарын ______ елда______сум күләмендә кертергә.

3. Җыелган үзара салым средстволарын җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:____________________________________________.

4. Әлеге карарны________________________ территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында" (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайты "Интернет" челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче